| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ШЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>Улица Колхозная, дом 1,<br>село Шланга, 422474<br>ИНН 1617003275 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЛАНГА АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>Колхоз урамы, 1нче йорт,<br>Шланга авылы, 422474 |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.09.2018 ел № 28

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәренең коррупциягә каршы тору стандартына үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законнар, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге башкарама комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәренең Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге башлыгының 2017 елның 27 октябрендәге 11 номерлы(2018 елның 6 июнендәге 17 номерлы редакциясендә) карары белән расланган коррупциягә каршы тору стандартына түбәндәге үзгәреш кертергә:

4 пунктның 4.2 пунктындагы 2 абзацын киләсе редакциядә бәян итәргә:

"оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез катнашу Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә рөхсәт ителә;

муниципаль берәмлек булып торган оешманың идарә органнарында һәм Ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) муниципаль хокукый актлар нигезендә муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль милектә булган акцияләрне (устав капиталында катнашу өлешләре) гамәлгә кую тәртибен билгели торган һәм федераль законнарда каралган башка очракларда рөхсәт ителә;".

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы

Чүпрәле муниципаль районы
Шланга авыл җирлеге башлыгы: А. А. Мөхәррәмов